**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам противодействия коррупции**

В связи с изменениями в федеральном законодательстве по вопросам противодействия коррупции **постановляю:**

1. Установить, что лица, претендующие на замещение должностей и замещающие должности, осуществление полномочий по которым влечет за собой обязанность представлять сведения о своих доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, представляют такие сведения по форме справки, утвержденной Указом Президента Российской Федерации от 23 июня 2014 года № 460 «Об утверждении формы справки о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера и внесении изменений в некоторые акты Президента Российской Федерации».

2. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 30 декабря 2009 года № УП-702 «О представлении гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711, от 16 мая 2012 года № УП-343 и от 22 апреля 2013 года № УП-328) следующие изменения:

а) абзацы третий – седьмой пункта 1 признать утратившими силу;

б) в Положении о представлении гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера:

в пунктах 3 и 4 слова «по утвержденным формам справок» заменить словами «по утвержденной Президентом Российской Федерации форме справки»;

абзац второй пункта 9 изложить в следующей редакции:

«Гражданский служащий может представить уточненные сведения в течение одного месяца после окончания срока, указанного в пункте 4 настоящего Положения. Гражданин, назначаемый на должность государственной службы, может представить уточненные сведения в течение одного месяца со дня представления сведений в соответствии с пунктом 3 настоящего Положения.».

3. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 11 января 2010 года № УП-4 «О представлении гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 мая 2012 года № УП-343, от 22 апреля 2013 года № УП-330 и от 20 августа 2014 года № УП-797) следующие изменения:

а) абзацы третий – седьмой пункта 1 признать утратившими силу;

б) в Положении о представлении гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера:

в пункте 3 слова «по утвержденным формам справок» заменить словами «по утвержденной Президентом Российской Федерации форме справки»;

абзац второй пункта 8 изложить в следующей редакции:

«Лицо, замещающее государственную должность Республики Татарстан, может представить уточненные сведения в течение одного месяца после окончания срока, указанного в пункте 4 настоящего Положения. Гражданин, претендующий на замещение государственной должности Республики Татарстан, может представить уточненные сведения в течение одного месяца со дня представления сведений в соответствии с пунктом 3 настоящего Положения.».

4. Внести в Положение о комиссиях по соблюдению требований к служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 25 августа 2010 года № УП-569 «О комиссиях по соблюдению требований к

служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 6 ноября 2013 года № УП-1084 и от 20 августа 2014 года № УП-797), следующие изменения:

а) пункт 15 дополнить подпунктом «д» следующего содержания:

«д) поступившее в соответствии с частью 4 статьи 12 Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» в государственный орган уведомление коммерческой или некоммерческой организации о заключении с гражданином, замещавшим должность государственной службы в государственном органе, трудового или гражданско-правового договора на выполнение работ (оказание услуг), при условии, что указанному гражданину комиссией ранее было отказано во вступлении в трудовые и гражданско-правовые отношения с указанной организацией или что вопрос о даче согласия такому гражданину на замещение им должности в коммерческой или некоммерческой организации либо на выполнение им работы на условиях гражданско-правового договора в коммерческой или некоммерческой организации комиссией не рассматривался.»;

б) дополнить пунктами $16^1$ - $16^3$ следующего содержания:

«$16^1$. Обращение, указанное в абзаце втором подпункта «б» пункта 15 настоящего Положения, подается гражданином, замещавшим должность государственной службы в государственном органе, в подразделение кадровой службы государственного органа по профилактике коррупционных и иных правонарушений либо должностному лицу кадровой службы государственного органа, ответственному за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений. В обращении указываются: фамилия, имя, отчество гражданина, дата его рождения, адрес места жительства, замещаемые должности в течение последних двух лет до дня увольнения с государственной службы, наименование, местонахождение коммерческой или некоммерческой организации, характер ее деятельности, должностные (служебные) обязанности, исполняемые гражданином во время замещения им должности государственной службы, функции по государственному управлению в отношении коммерческой или некоммерческой организации, вид договора (трудовой или гражданско-правовой), предполагаемый срок его действия, сумма оплаты за выполнение (оказание) по договору работ (услуг). В подразделении кадровой службы государственного органа по профилактике коррупционных и иных правонарушений либо должностным лицом кадровой службы государственного органа, ответственным за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений, осуществляется рассмотрение обращения, по результатам которого подготавливается мотивированное заключение по существу обращения с учетом требований статьи 12 Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции». Обращение, заключение и другие материалы в течение двух

рабочих дней со дня поступления обращения представляются председателю комиссии.

$16^{2}$. Обращение, указанное в абзаце втором подпункта «б» пункта 15 настоящего Положения, может быть подано государственным служащим, планирующим свое увольнение с государственной службы, и подлежит рассмотрению комиссией в соответствии с настоящим Положением.

$16^{3}$. Уведомление, указанное в подпункте «д» пункта 15 настоящего Положения, рассматривается подразделением кадровой службы государственного органа по профилактике коррупционных и иных правонарушений либо должностным лицом кадровой службы государственного органа, ответственным за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений, которое осуществляет подготовку мотивированного заключения о соблюдении гражданином, замещавшим должность государственной службы в государственном органе, требований статьи 12 Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции». Уведомление, заключение и другие материалы в течение десяти рабочих дней со дня поступления уведомления представляются председателю комиссии.»;

в) подпункт «а» пункта 17 дополнить словами «, за исключением случаев, предусмотренных пунктами $17^{1}$ и $17^{2}$ настоящего Положения»;

г) дополнить пунктами $17^{1}$ и $17^{2}$ следующего содержания:

«$17^{1}$. Заседание комиссии по рассмотрению заявления, указанного в абзаце третьем подпункта «б» пункта 15 настоящего Положения, как правило, проводится не позднее одного месяца со дня истечения срока, установленного для представления сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера.

$17^{2}$. Уведомление, указанное в подпункте «д» пункта 15 настоящего Положения, как правило, рассматривается на очередном (плановом) заседании комиссии.»;

д) пункты 18 и 19 изложить в следующей редакции:

«18. Заседание комиссии проводится в присутствии государственного служащего, в отношении которого рассматривается вопрос о соблюдении требований к служебному поведению и (или) требований об урегулировании конфликта интересов, или гражданина, замещавшего должность государственной службы в государственном органе. При наличии письменной просьбы государственного служащего или гражданина, замещавшего должность государственной службы в государственном органе, о рассмотрении указанного вопроса без его участия заседание комиссии проводится в его отсутствие. В случае неявки на заседание комиссии государственного служащего (его представителя) или гражданина, замещавшего должность государственной службы в государственном органе (его представителя), при отсутствии письменной просьбы государственного служащего или указанного гражданина о рассмотрении данного вопроса без его участия рассмотрение вопроса откладывается. В случае повторной неявки указанных лиц без уважительных причин комиссия может принять решение о

рассмотрении данного вопроса в отсутствие государственного служащего или гражданина, замещавшего должность государственной службы в государственном органе.

19. На заседании комиссии заслушиваются пояснения государственного служащего или гражданина, замещавшего должность государственной службы в государственном органе (с их согласия), и иных лиц, рассматриваются материалы по существу вынесенных на данное заседание вопросов, а также дополнительные материалы.»;

е) дополнить пунктом $25^1$ следующего содержания:

«$25^1$. По итогам рассмотрения вопроса, указанного в подпункте «д» пункта 15 настоящего Положения, комиссия принимает в отношении гражданина, замещавшего должность государственной службы в государственном органе, одно из следующих решений:

а) дать согласие на замещение им должности в коммерческой или некоммерческой организации либо на выполнение работы на условиях гражданско-правового договора в коммерческой или некоммерческой организации, если отдельные функции по государственному управлению этой организацией входили в его должностные (служебные) обязанности;

б) установить, что замещение им на условиях трудового договора должности в коммерческой или некоммерческой организации и (или) выполнение в коммерческой или некоммерческой организации работ (оказание услуг) нарушают требования статьи 12 Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции». В этом случае комиссия рекомендует руководителю государственного органа проинформировать об указанных обстоятельствах органы прокуратуры и уведомившую организацию.»;

ж) дополнить пунктом $36^1$ следующего содержания:

«$36^1$. Выписка из решения комиссии, заверенная подписью секретаря комиссии и печатью государственного органа, вручается гражданину, замещавшему должность государственной службы в государственном органе, в отношении которого рассматривался вопрос, указанный в абзаце втором подпункта «б» пункта 15 настоящего Положения, под роспись или направляется заказным письмом с уведомлением по указанному им в обращении адресу не позднее одного рабочего дня, следующего за днем проведения соответствующего заседания комиссии.».

5. Внести в пункт 1 Положения о проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, и соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению, утвержденного Указом Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711 «О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной

гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, и соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 мая 2012 года № УП-343 и от 6 ноября 2013 года № УП-1084), следующие изменения:

а) в подпункте «а»:

в абзаце первом слово «представляемых» заменить словом «представленных»;

в абзаце третьем слова «по состоянию на конец отчетного периода» заменить словами «за отчетный период и за два года, предшествующие отчетному периоду»;

б) в подпункте «б» слово «представляемых» заменить словом «представленных»;

в) подпункт «в» изложить в следующей редакции:

«в) соблюдения гражданскими служащими в течение трех лет, предшествующих поступлению информации, явившейся основанием для осуществления проверки, предусмотренной настоящим подпунктом, ограничений и запретов, требований о предотвращении или урегулировании конфликта интересов, исполнения ими обязанностей, установленных Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» и другими федеральными законами, а также нормативными правовыми актами Республики Татарстан (далее – требования к служебному поведению).».

6. Внести в пункт 1 Положения о проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, и лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, и соблюдения ограничений лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, утвержденного Указом Президента Республики Татарстан от 22 апреля 2011 года № УП-233 «О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, и лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, и соблюдения ограничений лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 мая 2012 года № УП-343, от 6 ноября 2013 года № УП-1084 и от 20 августа 2014 года № УП-797), следующие изменения:

а) в подпункте «а»:

слово «представляемых» заменить словом «представленных»;

слова «по состоянию на конец отчетного периода» заменить словами «за отчетный период и за два года, предшествующие отчетному периоду»;

б) в подпункте «б» слово «представляемых» заменить словом «представленных»;

в) подпункт «в» изложить в следующей редакции:

«в) соблюдения лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, в течение трех лет, предшествующих поступлению информации, явившейся основанием для осуществления проверки, предусмотренной настоящим подпунктом, ограничений и запретов, требований о предотвращении или урегулировании конфликта интересов, исполнения ими должностных обязанностей, установленных Федеральным законом «О противодействии коррупции», другими федеральными законами, Законом Республики Татарстан «О государственных должностях Республики Татарстан» и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан (далее – установленные ограничения).».

7. Настоящий Указ вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящим пунктом установлен иной срок вступления в силу.

Пункт 1, подпункт «а», абзац второй подпункта «б» пункта 2, подпункт «а», абзац второй подпункта «б» пункта 3 вступают в силу с 1 января 2015 года.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
24 сентября 2014 года
№ УП-920

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләренә кагылышлы аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Федераль законнарда коррупциягә каршы тору мәсьәләләренә кагылышлы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Алар буенча вәкаләтләр башкару үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү йөкләнгән вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы һәм аларны биләүче затлар мондый белешмәләрне Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча бирәләр дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы һәм 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның өченче – җиденче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында,

мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәдә:

3 һәм 4 пунктларда «расланган белешмәләр формасы буенча» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча» сүзләренә алмаштырырга.

9 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан хезмәткәре әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң бер ай дәвамында төгәллек кертелгән белешмәләрне бирә ала. Дәүләт хезмәтенә билгеләп куела торган граждан әлеге Нигезләмәнең 3 пункты нигезендә белешмәләр бирелгән көннән бер ай дәвамында төгәллек кертелгән белешмәләрне бирә ала.».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-330 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның өченче – җиденче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәдә:

3 пунктта «расланган белешмә формалары буенча» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң бер ай дәвамында төгәллек кертелгән белешмәләрне бирә ала. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы граждан әлеге Нигезләмәнең 3 пункты нигезендә белешмәләр бирелгән көннән бер ай дәвамында төгәллек кертелгән белешмәләрне бирә ала.».

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 15 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» пункты өстәргә:

«д) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт шартнамәсе яисә гражданлык-хокукый шартнамә төзү турындагы «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше нигезендә дәүләт органына бирелгән хәбәрнамәсе әлеге гражданга комиссия тарафыннан алдарак бу оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләренә һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керү тыелган яисә әлеге гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында аның тарафыннан эшләр башкаруга рөхсәт бирү мәсьәләсе каралмаган булса.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ - $16^3$ пунктларын өстәргә:

«$16^1$. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел яисә башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча бүлекчәсенә яисә дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел яисә башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи затына бирелә. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туган көне, торган урынының адресы, дәүләт хезмәтеннән киткәнче кадәр ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешма урнашкан җир, аның эшчәнлеге характеры, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгәндә граждан тарафыннан башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага мөнәсәбәтле дәүләт идарәсе буенча функцияләре, шартнамә төре (хезмәт һәм гражданлык-хокукый), якынча аның гамәле вакыты, шартнамә буенча башкарылган (күрсәтелгән) эш (хезмәт) өчен түләү суммасы. Дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел яисә башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча бүлекчәсендә яисә дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел яисә башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне карап тикшерә, аның йомгаклары буенча «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273

номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилле бәяләмә әзерләнә. Мөрәҗәгать, бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать кабул ителгәннән соң ике эш көне дәвамында комиссия рәисенә бирелә.»;

16². Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелергә мөмкин һәм ул комиссия тарафыннан әлеге Нигезләмәгә таянып каралырга тиеш.

16³. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы «Коррупциягә каршы тору» Федераль законының 12 статьясы таләпләре үтәлүе турындагы дәлилле бәяләмәләрне әзерләү белән шөгыльләнүче дәүләт органы кадрлар хезмәте бүлекчәсе яисә коррупциячел яисә башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карап тикшерелә. Хәбәрнамә, бәяләмә һәм башка материаллар хәбәрнамә алынган көннән ун эш көне дәвамында комиссия рәисенә бирелә.»;

в) 17 пунктның «а» пунктчасына «, әлеге Нигезләмәнең 17¹ һәм 17² пунктларында каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

г) түбәндәге эчтәлекле 17¹ һәм 17² пунктларын өстәргә:

«17¹. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән гаризаны карау комиссиясе утырышы, гадәттә, керемнәр турында, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында бирелгән мәгълүматлар тапшыруга билгеләнгән вакыт тәмамланганнан соң бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

17². Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.»;

д) 18 һәм 19 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Комиссия утырышы аңа карата хезмәт урынында үз-үзеңне тотуга карата таләпләрнең йә (яисә) мәнфәгатьләр каршылыкларын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре яисә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан катнашында уздырыла. Дәүләт хезмәткәре яисә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның әлеге мәсьәләне аннан башка гына карап тикшерү турында язма үтенече булганда, комиссия утырышы аннан башка гына уздырыла. Дәүләт хезмәткәре (аның вәкиле) яисә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан (аның вәкиле) комиссия утырышына килмәгәндә, дәүләт хезмәткәренең һәм әлеге гражданның бу мәсьәләне аның катнашыннан башка гына карау турындагы язмача үтенече булмаганда, мәсьәләне карап тикшерү кичектерелә. Аталган затларның нигезле сәбәпләрсез утырышка килмәве кабатланганда, комиссия әлеге мәсьәләне дәүләт хезмәткәреннән яисә дәүләт органында дәүләт

хезмәте биләгән гражданнан башка гына карап тикшерү турында карар кабул итәргә мөмкин.

19. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яисә дәүләт органында дәүләт хезмәте биләгән гражданның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка куелган мәсьәләләр буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карап тикшерелә.»;

е) түбәндәге эчтәлекле 25[1] пунктын өстәргә:

«25[1]. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча дәүләт органында дәүләт хезмәте биләгән гражданга карата әлеге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, аңа вазыйфа биләүгә яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирергә;

б) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләү яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкару (хезмәт күрсәтү) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләре бозылуга китерә дип билгеләргә. Бу очракта комиссия дәүләт органы җитәкчесенә әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәр биргән оешмага мәгълүмат бирергә тәкъдим итә.»;

ж) түбәндәге эчтәлекле 36[1] пунктын өстәргә:

«36[1]. Комиссия карарыннан аның секретаре имзасы һәм дәүләт органы мөһере белән расланган күчермә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, аңа кагылышлы әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга кул куйдырып тиешле комиссия утырышы уздырылган көннән соң килүче бер эш көненнән дә кичектермичә бирелә яисә аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча хәбәрнамәле заказлы хат белән җибәрелә.».

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы һәм 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне

дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәнең 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «а» пунктчасында:

беренче абзацта «бирелә торган» сүзләрен «бирелгән» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацтагы «хисап чоры ахырына булгандагыча» сүзләрен «хисап чорына һәм хисап чоры алдыннан килгән ике елга» сүзләренә алмаштырырга;

б) «б» пунктчасында «бирелә торган» сүзләрен «бирелгән» сүзенә алмаштырырга;

в) «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге пунктчада каралган тикшерүне гамәлгә ашыру өчен нигез булып торган мәгълүмат алынганчы өч ел дәвамында граждан хезмәткәрләренең чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр каршылыкларын булдырмау яисә җайга салу таләпләрен үтәүләре, алар тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда, шулай ук Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вазыйфаларны башкаруы (алга таба – хезмәт урынындагы тәртипкә таләпләр).».

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында» 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәнең 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «а» пунктчасында:

«бирелә торган» сүзләрен «бирелгән» сүзенә алмаштырырга;

«хисап чоры ахырына булгандагыча» сүзләрен «хисап чорына һәм хисап чоры алдыннан килгән ике елга» сүзләренә алмаштырырга;

б) «б» пунктчасында «бирелә торган» сүзләрен «бирелгән» сүзенә алмаштырырга;

в) «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның әлеге пунктчада каралган тикшерүне гамәлгә ашыру өчен нигез булып торган мәгълүмат алынганчы өч ел дәвамында чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр каршылыкларын булдырмау яисә җайга салу таләпләрен үтәүләре, алар тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән вазыйфаларны башкарулары (алга таба – билгеләнгән чикләүләр).».

7. Әлеге Указ, әлеге пункт нигезендә үз көченә керүенең башка вакыты билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

1 пункт, 2 пунктның «а» пунктчасы, «б» пунктчасының икенче абзацы, 3 пунктның «а» пунктчасы, «б» пунктчасының икенче абзацы 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2014 ел, 24 сентябрь
№ ПУ-920